УДК 821.512.145:821.512.162

*К.М. Миңнуллин*

# ТӨРКИ ӘДӘБИЯТЛАР БАГЛАНЫШЛАРЫ
## (Тукай һәм Сабир иҗатлары мисалында)

В статье рассматривается творчество поэтов Габдуллы Тукая и Сабира в контексте взаимодействия тюркских (татарской и азербайджанской) литератур.

**Ключевые слова:** Габдулла Тукай, татарская литература начала XX века, Сабир, азербайджанская литература.

Совет дәвере үтеп 1980 еллар ахырыннан илдә демократик үзгәртеп кору башлангач, милли үзаң үсеше, төрки халыкларның милли тәңгәллекләрен кабат торгызу омтылышы, бер яктан, әдәбиятларның милли үзенчәлекләрен мөмкин кадәр тирәнрәк өйрәнү, икенче яктан, аның гомумкешелек, гомумтөрки мәдәниятенең аерылгысыз өлеше булуын тою кирәклеге мәсьәләсен алдыбызга куйды. Бу быел 130 еллык юбилее билгеләп үтелгән бөек шагыйребез Габдулла Тукай мирасын өйрәнү мисалында да ачык сизелә. Әдәбият турындагы фән Тукай иҗатындагы милли үзенчәлекләрне өйрәнүгә никадәр тирәнрәк үтеп керсә, аның әсәрләрендәге гомумтөрки тамырлар шулкадәр ныграк ачыла бара. Шагыйрь иҗатын гомумтөрки әдәбиятлар яссылыгында карарга омтылышның көчәя баруы да шуның белән аңлатыла.

Совет чорында әдәбиятлар арасындагы багланышлар, шул исәптән төрки телле әдәбиятларның үзара мөнәсәбәтләре дә, бер генә яклы аңлатылып килende. Ул рус сүз сәнгатенең башка халыклар әдәбиятына йогынтысы яки алдарак иҗат ителгән әдәби әсәрләрнең соңрак чорларда иҗат мәйданына килгән язучыларга тәэсире итеп каралды.

Әмма әдәбият фәненең үсеше, төрле сәбәпләр нәтиҗәсендә озак вакытлар дәвамында киңкатлам укучылар игътибарыннан читтә кала килгән рухи мирасыбызның кабат кайтарылуы төрки телле әдәбиятларда үзенчәлекле сәнгать күренешләренең, әдәбиятларның үзара тәэсире нәтиҗәсендә генә түгел, ә социомәдәни, милли бергәлекләрнең рухи үсеше буларак яшәвен торган саен ныграк дәлилли. Г. Тукай һәм Сабир иҗатлары мисалында XX гасыр башы татар һәм азәрбайҗан әдәбиятларын чагыштыру да шундый нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирә.

Һичшиксез, бу чорда Казандагы һәм Бакудагы иҗтимагый-сәяси шартлар бик тә охшаш була: XIX гасырдагы мәгърифәтчелек хәрәкәте, 1905 елгы инкыйлаб дулкынында күз алдына китермәслек мәдәни югарылыкка ирешү әдәбият мәйданында тормышларын да, иҗат-

ларын да үз халыкларын милли яңарышка алып чыгуны максат иткән Г. Тукай, С. Рәмиев, Н. Нариманов, Г. Сабир кебек бер төркем фикер ияләрен тудыра. Әлеге иҗтимагый-мәдәни хәрәкәтнең үзәгендә кайнаган башка бик күп зыялыларыбызның исемнәрен дә атап үтәргә мөмкин. Алар укыту, тәрбия бирү, гаилә мөнәсәбәтләре, хатын-кыз һ.б. мәсьәләләргә караган иске тәртипләр һәм карашларны юк итү өчен хәлиткеч көрәш алып баралар. Милләтәшләренең яшәешен үзгәртү өчен көрәш аларның эшчәнлеген генә түгел, ә иҗатларының юнәлешен, идея эчтәлеген дә билгеле. Милли яңарыш хәрәкәтенә хезмәт итү татар һәм азәрбайҗан шагыйрләре һәм язучылары алдындагы беренче бурыч булып тора. Шул бурычны үтәргә омтылыш иске, катып калган мөселман тормышына, аерым дин әһелләренең реакцион карашларына, социаль һәм милли изүгә каршы ачыктан-ачык көрәшкә башлангыч биргән сатирик журналлар туугa сәбәп була. «Мелла Насретдин», «Зәнбур» («Шөпшә»), «Уклар», «Карчыга», «Яшен» һәм башка журналлар менә шундыйлардан.

«Мелла Насретдин» журналы азәрбайҗан халкының төп милли трибунасы булып, алдынгы җәмәгатьчелекнең, шул исәптән татарларның да, тиз арада игътибарын үзенә җәлеп итә [Касумов, с. 4]. Журнал җирле материаллар белән генә чикләнмичә, бөтен Россия империясендәге вакыйгалар турында хәбәрләр бастыра, Кавказда, Урта Азиядә, Казахстанда, Идел буенда, Төркиядә, Иранда аеруча танылуга ирешә [Качарли, с. 7]. Журналның күп кенә номерларында, Казан хәбәрчеләре җибәргән, татарлар тормышы турында кыска күзәтүләр, сатирик язмалар, татар кадимчеләренә карикатуралар урнаштырыла. Моннан тыш, Идел һәм Урал буе татарлары азәрбайҗанның «Ени хагигат» («Яңа хакыйкать»), «Иршад» («Юл күрсәтүче»), «Таза хәят» («Яңа тормыш») «Каспий», газеталарын, «Деблетан» («Мәктәп») журналын һ.б. алып укыйлар [Нафигов, Циунчук, с. 75]. Шулай ук «мәнфәгати» дуслык та урнаша: «Әл-ислах» «Мелла Насретдин» язмаларына сылтама белән Босния һәм Герцеговина, Төркиядә һәм Иранда барган вакыйгаларны яктырта яки анда басылганнарны кыскача сөйләп чыга. «Урал» газетасы редакциясе инде 1907 елларда ук үзенең битләрендә Казаннан җибәрелгән шигырьләрне бастырган «Текамюль» газетасы редакциясе белән тыгыз бәйләнештә була һ.б. [Нафигов, с. 103–107].

«Мелла Насретдин» журналын укучылар арасында, аны беренче саныннан ук яздырып алучы, Г. Тукай да була. Әле Җаек шәһәрендә вакытта төшкән бер рәсемендә үк без аның кулына «Мелла Насретдин» журналы тотканлыгын күрәбез.

Ул даими рәвештә бу журнал тирәсенә тупланган азәрбайҗан әдипләре, бигрәк тә, «Сабир» (сабыр) тәхәллүсе белән танылган ялкынлы шагыйрь Галиәкбәр Таһирзадә (1862–1911), шулай ук журналның мөхәррире Җәлил Мәмәдкулизадә иҗатлары белән

кызыксына [Гумматова, с. 155–156]. Г. Тукай үзе дә 1906 елда Җаекта «Уклар» дип исемләнгән татар телендәге беренче сатирик журналны чыгаруда актив катнаша.

Тукай һәм Сабир әдәбиятка мәгърифәтчелек реализмы вәкилләре буларак аяк басалар һәм 1905 елгы инкыйлаби күтәрелеш аларның иҗатын үстерә. Тарихи шартлар яшь шагыйрьләрне тиз арада илне яклап иң куярлык иргә әверелдерә, иҗатларында да кискен күтәрелеш сизелә. Ике шагыйрь дә гыйлемлелек, белем ярдәмендә җәмгыятьтәге шартларны үзгәртеп корып булачагына ышаналар. Азәрбайҗан шагыйренең замандашы Сәет Хөсәен: «Сүз остасы, шагыйрь Сабир үзенең бурычын халыкка хезмәт итүдә, аны уяту өчен көрәштә күрде» [кара: Алмасова], – дип яза.

Шул ук вакытта милли яңарыш хәрәкәтенең җитди йогынтысын кичергән Тукай һәм Сабир иҗатындагы реализм XIX гасырдагы мәгърифәтчелек реализмыннан нык кына аерылып тора. Алардагы мәгрифәтчелек карашлары «халык массаларының иске яшәеш формаларына каршы көрәшергә тиешлеген тану» [Абдуллин, Амирханов, с. 50] белән тыгыз бәйләнгән. Тиздән алар иҗатында тормышны реалистик сурәтләү арта барып, мәгърифәтчелек идеаллары миллилеккә урын бирәләр, иске феодаль һәм урта гасырлардан килгән гадәтләрне тәнкыйтьләү яшәп килгән тәртипләргә кискен каршы чыгу белән кушыла. Бу Тукай һәм Сабир иҗатындагы иҗади методларның да үзгәреше тудыра: 1906 елның икенче яртысыннан мәгърифәтчелек реализмы әкеренләп тәнкыйди реализмга юнәлеш тота. Азәрбайҗан әдәбияты белгече Я. Кариев: «Сабирның журналга килүе белән (“Мелла Насретдин”. – *К.М.*) тәнкыйди реализм үзәне тулыша. Ярның аерым урыннарында яңа төр реализмның “чикләре” күренә» [Караев, с. 265], – дип яза. Ике шагыйрьнең дә реализмы ачыктан-ачык социаль характерга ия.

Билгеле, һәр ике шагыйрьнең дә үз юлы, үзенең поэтик жанры бар. Сатира Сабир иҗатының иң төп җанры булып тора. Әмма алар сайлаган бу юлны бары шигърияттәге язмыш дип кенә дә атап булмый. XX гасыр башында Россиядә, аның үзәктән читтә булган өлкәләрендә, өлешчә Бакуда да, халыкның ризасызлыгы әлегә кадәр күрелмәгән чиккә җитә. Сәяси вакыйгалар йогынтысы, бигрәк тә Бакудагы декабрь стачкасы тәэсирендә азәрбайҗан авыллары кузгала. Шулар Сабирны сатирик әсәрләр язарга рухландыра, аның шигърияте иреккә, мәгърифәтле булырга өнди, хатын-кыз азатлыгын яклап чыга [Алмасова].

Башка халыклардан артта калган, кара наданлыкта, фанатизмда яшәүче милләт образы Сабир шигырьләренең күпчелегендә чагылыш таба. А. Гаджиев фикеренчә, аның мондый әсәрләре «Йокыга талган патшалык» сатирик шигырьләр циклын тудыра. «Бу М.Ф. Ахундовта да, Н. Вәзировта да, Н. Наримановта да булмады. Йоклаган милләт

образы “Мелла Насретдин” журналында барлыкка килде, аның төп поэтик иҗатчысы Сабир булды» [Гаджиев, с. 161], – дип яза ул. Еллар үтү белән, татар әдәбиятындагы кебек үк, бу образ азәрбайҗан әдәбиятының да яңарыш хәрәкәте шигаре булып әверелә. Әмма тарихи-мәдәни хәрәкәт, мохит уртаклыгы, ике халыкның матбугат органнары арасындагы тыгыз бәйләнешләренә карамастан, бу образның татар һәм азәрбайҗан әдәбиятларында барлыкка килүе тышкы тәэсир нәтиҗәсендә түгел, ә һәр ике әдәбиятта да нәкъ катлаулы эчке үзгәрешләр нәтиҗәсе буларак туганлыгы дәлилләнә. Сабир иҗатында беренче булып бу образ «Минем ни эшем бар?» (28.04.1906) шигырендә урын ала. Шагыйрь ирония белән:

Тсс! Не шуми! Пусть люди спят.
Я не желаю,
Чтоб спящих подняли, глаза им
раскрывая [Стихи Сабира], –

дип яза.

Лирик герой үзе яшәгән чордагы азәрбайҗан җәмгыятенең халәтен йокы халәте дип бәяләп, «Минем туган халкымны әйдә таласыннар – анда минем ни эшем бар?» – дигән гыйбарәне берничә тапкыр кабатлый. Бу гыйбарәне ике мәгънәдә – матди байлыкларны һәм рухи көчне югалту буларак аңларга мөмкин. «Йоклап ятучы җәмгыять» үзенең асыл кыйммәтләрен ничек юк итүләрен аңламый да кала.

«Киләчәк өчен хезмәт ит» (25.08.1906) шигырендә йокы халәте эшлексезлек, кәеф-сафа корып яшәү, наданлык, хокуксызлык буларак аңлашыла. Лирик герой үз халкына мөрәҗәгать итеп кат-кат сорый:

Народ мой, будешь в крепкий сон
ты погружен – доколе?
Постельных радостей искать,
считать ворон – доколе?
На эту спячку, праздность, лень ты
обречен – доколе?
Ислам в невежестве погряз, мир
ослеплен – доколе?
Терпеть убогость, темноту, и плач,
и стон – доколе?
Народ забит и угнетен, бесправен
он – доколе? [Стихи Сабира]

Күргәнебезчә, шигырь драматик һәм трагик яңгыраш алган. Йокы азәрбайҗан җәмгыяте яшәешенең барлык өлкәләрендә дә артта калганлыгын тәнкыйтьли. Шул ук идея 1906 елның 11 августында язылган исемсез шигырендә дә ачык сизелә:

Темнота кругом, дитя, ляг, усни
ты, не проснись,
Сон неведенья от глаз не гони ты,
не проснись!
Бай-бай, малыш, бай-бай,
Так всё проспишь, бай-бай!

(…) Ах, открыв глаза, вокруг лишь
беду увидишь ты,
У народа скорбь одну и нужду
увидишь ты,
Горя, зла, страданий, мук череду
увидишь ты.
Под подушку – головой! В эти дни
ты не проснись!
Бай-бай, малыш, бай-бай,
Так всё проспишь, бай-бай!

Шул рәвешчә, Сабир иҗатындагы йокы һәм йокыга талган патшалык образлары чынбарлыкка ироник бәя бирү өчен

кулланыла, әлеге образлар катнашкан барлык текстларда да диярлек үз халкын «уятырга теләге булмаган» милләттәшләрен тәнкыйтьләү, көлкегә калдыру сизелә. Метафоралаштыру алымы структура тудырырга ярдәм итсә, ирония «үз-үзеңне фаш итү» нәтиҗәсендә барлыкка килә.

Шул ук образ башка статуста Г. Тукай иҗатында да (шулай ук С. Рәмиев, М. Гафури, Н. Думави иҗатларында да) калкып чыга. Монда инде ирония генә түгел, үтергеч сатирага өстенлек бирелә, мәгънә тудыру алымы да – символлаштыру. 1906 елның 17 апрелендә Г. Тукайның «Безнең милләт үлгәнме, әллә йоклаган гынамы?» мәкаләсе басыла. Ул анда башка халыклар үсешкә омтылганда аңын югалтып, сабый йокысына талган милләт сурәтен тудыра. Милләткә аның үз халәтен чагылдырган әдәбият, вакытлы матбугат, музыка, берләшү идеяләре («иттифак сулары») аңына килергә ярдәм итәр дип ышана. Сатира турыдан-туры бәяләү һәм детальләштерү ярдәмендә туа.

Г. Тукай С. Рәмиевнең «Уку» шигыренә охшатып язылган «Йокы» (1908 ) шигырендә:

Безне адәм иткән йокы,
Адәмне алга илткән йокы,
Илтеп күккә җиткән йокы, –
Йокы, йокы, йокы –
[Тукай, б. 264],

дип белдерә.

Әлеге шигырьгә бирелгән шәрехләүдә: «Йокы шундый яхшы эш булса, татарлар күптән алга киткән булырлар иде», – дип искәртә. Бу сүзләр Сабир иҗаты белән аваздаш. Әмма С. Рәмиев шигыре белән интертекстуаль бәйләнеш Тукайга ике төшенчәне – йокы һәм уку төшенчәләрен капма-каршы куярга мөмкинлек бирә, икенчесе аша беренчесе детальләштерелә, нәтиҗәдә образ символик мәгнәгә ия була.

Бер елга алдарак язылып, Тукай тарафыннан «татар маршы» дип аталган «Тартар кошы сайрый» шигыре «татарның йокыдан уянуы»на мөнәсәбәтле шатлык, өмет хисләре белән сугарылган:

Уйкудан тиз тора татар;
Тора! Тора! Тора татар;
Баш күтәргән бар татар!
[Тукай, б. 156]

Тиздән татар шигърияте ндә (Н. Думави «Йоклыйлар» (1906), «Караңгылык каплап тора татарны» (1906), С. Рәмиев «Бел телен, эзлә юлын» (1906), «Таң вакыты» (1908), З. Бурнашева «Туар әле кояшлы көн» һ.б.), публицистикасында, хәтта лиро-эпик жанрда да (Ф. Әмирханның «Шәрык йоклый» нәсере) йокы образы ныгып китә. Һәр текстта йокы образын символлаштыру чагылыш таба. Шулай итеп татар әдәбиятында йокы образы әйдәп баручы лейтмотивка әверелә Аның аша иҗтимагый-сәяси тормышка битарафлык, караңгы яшәештән канәгать булып алгарышка омтылмый көн күрү тәнкыйть ителә. Татар язучылары җәмгыятьне уянырга, алдынгы илләрдән, халыклардан үрнәк алырга чакыралар. «Уянырга», димәк, алгарыш, азатлык юлына аяк басарга, ул – яңарышка хәрәкәт символы. Әлеге мисаллар ярдәмендә

генә дә XX гасыр башында төрки халыклар әдәбиятында бер-берсенә бәйсез рәвештә милли яңарыш символына әверелгән күренешләр, ишарә образлар һәм мотивларның үзара керешкәнлеген күрәбез. Бу милли бергәлекләрдә социомәдәни процесслар гына түгел, милли әдәбиятларның үсеш юлы да охшаш булганлыгы ачык аңлашыла. Мондый нәтиҗә тагын бер кат төрки халыкларның әдәбиятлары арасындагы бәйләнешләрне өйрәнүгә яңача якын килү мәсьәләсен хәл итү кирәклеген күрсәтә.

**Әдәбият**

*Абдуллин Я.Г., Амирханов Р.К.* Развитие общественно-политических взглядов Тукая // Габдулла Тукай. Материалы научной конференции и юбилейных торжеств, посвященных 80-летию со дня рождения поэта. Казань: Татар. кн. изд-во, 1979.

*Алмасова Э.* «Призван я быть поэтом. Стих – честный голос мой» // Азербайджанские известия. 2012. 19 мая.

*Гаджиев А.* Азербайджанский реализм. Баку: Язычы, 1983.

*Гумматова Х.* Габдулла Тукай и «Молла Насреддин» // Габдулла Тукай и тюркский мир: материалы международной конференции, посвященной 130-летию со дня рождения Г. Тукая. Казань: ИЯЛИ, 2016. С. 155–156.

*Караев Я.* Этапы азербайджанского реализма. Баку: Язычы, 1983.

*Касумов М.Х.* Боевой революционно-сатирический журнал «Молла Насреддин» и его общественно-политическое направление (1906–1931 гг.). Баку: Изд-во АН АзССР, 1966.

*Качарли Ф.К.* Революционно-демократическая мысль в Азербайджане и Нариман Нариманов. Баку: Изд-во АН АзССР, 1966.

*Нафигов Р., Циунчук А.* В борьбе против царизма и буржуазного национализма / Из истории революционно демократических и марксистских кружков в Поволжье. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1983. С. 75.

*Нафигов Р.* Тайны революционного подполья. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1981. С. 103–107.

Стихи Сабира // portal21.ru›news/we_recommend.php…: карау вакыты: 07.04.2016 г.

*Тукай Габдулла.* Әсәрләр. Академик басма. Алты томда. Т. 1: Шигъри әсәрләр (1904–1908). Казань: Татар. кит. нәшр, 2011.

***Миңнуллин Ким Мөгаллим улы,***
*филология фәннәре докторы, профессор,*
*Татарстан Фәннәр академиясенең мөхбир әгъзасы,*
*Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры*